ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРУ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
“КОЛБАЙ МОРАСА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ”




“ ТАТАР ТЕЛЕН САКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ ”

ЮНӘЛЕШЕНӘ

**Тема:** *“Туган телдә яшь журналист мәктәбе”*

***Эшне башкарды:***

***11 нче сыйныф укучысы***

***Ахметзянова Айгөл Айрат кызы***

***Фәнни җитәкче:***

***туган тел һәм әдәбият укытучысы***

***Галиуллина Рәмзия Гасым кызы***




***Нурлат, 2026 нчы ел***

# Проектның паспорты:

*ПРОЕКТНЫҢ ИСЕМЕ: “ТУГАН ТЕЛДӘ ЯШЬ ЖУРНАЛИСТ МӘКТӘБЕ”*
*ПРОЕКТНЫҢ АВТОРЫ: АХМЕТЗЯНОВА АЙГӨЛ АЙРАТ КЫЗЫ*
*ПРОЕКТ ҖИТӘКЧЕСЕ: ГАЛИУЛЛИНА РӘМЗИЯ ГАСЫМ КЫЗЫ*
*ПРОЕКТНЫҢ ТИБЫ: КОМПЛЕКСЛЫ (ИҖАДИ, ФӘННИ-ЭЗЛӘНҮЛЕ)*
*ПРОЕКТНЫҢ ТӨРЕ: ШӘХСИ*

# *Максат:*

1)ЖУРНАЛИСТ ҺӨНӘРЕНЕҢ СЕРЛӘРЕНӘ ТӨШЕНДЕРҮ, АНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ НЕЧКӘЛЕКЛӘРЕ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ, ЭЗЛӘНҮЧӘН ШӘХЕС ФОРМАЛАШТЫРУ;
2)СҮЗНЕҢ МАТУРЛЫГЫН, ТУГАН ТЕЛНЕҢ КЕШЕ ТОРМЫШЫНДАГЫ АЛЫШТЫРГЫСЫЗ РОЛЕН УКУЧЫЛАРГА ТӨШЕНДЕРҮ;
3) УКУЧЫЛАРНЫ ӘЙЛӘНӘ – ТИРӘЛЕККӘ ИҖАДИ КАРАРГА ӨЙРӘТҮ, АЛАРНЫҢ ИҖАДИ ФИКЕРЛӘҮ СӘЛӘТЕН ҮСТЕРҮ;

4)ИНТЕРНЕТ ЧЕЛТӘРЕНДӘ АРАЛАШУ КУЛЬТУРАСЫН ӨЙРӘНҮ.

# Бурыч:

1) ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТ ЖАНРЛАРЫ, АНЫҢ  ТӨРЛӘРЕ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ;
2) АЗЕТА ЧЫГАРУДА ИҢ КИРӘКЛЕ БУЛГАН: ТЕМА ТАБУ, ФАКТЛАР ТУПЛАУ, ӘҢГӘМӘ ҮТКӘРҮ СЕРЛӘРЕНӘ ТӨШЕНДЕРҮ;
3) ГАЗЕТА ТЕЛЕ  ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕН ӨЙРӘТҮ;
4) ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАР БАСУ ТЕХНОЛОГИЯСЕ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ БИРҮ;
5) УКУЧЫНЫҢ ГАЗЕТА ЖАНРЛАРЫНА КАРАГАН МАТЕРИАЛЛАРНЫ ДӨРЕС ИТЕП ЯЗАРГА ӨЙРӘНҮЛӘРЕНӘ ИРЕШҮ;
6)БАЛАЛАРНЫҢ ФИКЕРЛӘҮ СӘЛӘТЛӘРЕН ҮСТЕРҮ, ИҖАТ АКТИВЛЫКЛАРЫН КИҢӘЙТҮ ;
7)ТАНЫП-БЕЛҮ ЭШЧӘНЛЕГЕН, ИҖАДИ ФИКЕРЛӘҮ СӘЛӘТЕН КАМИЛЛӘШТЕРҮ;
8) ЭСТЕТИК ЗӘВЫК ТӘРБИЯЛӘҮ.

## *Тикшеренү проблемасы:*

# ЖУРНАЛИСТИКА ЮНӘЛЕШЕ БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНУЧЫ ЯШЬЛӘРНЕҢ САНЫН АРТТЫРЫП, АЛАРНЫҢ ЯЗУ ҺӘМ ТЕЛДӘН СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫНДА КИТКӘН ХАТАЛАРНЫ ӨЙРӘНЕП, ТӨЗӘТҮ ЮЛЛАРЫН КҮРСӘТҮ.

# *Проектның идеясе:*

**ТАТАР ЖУРНАЛИСТИКАСЫНА  КЫЗЫКСЫНУ УЯТУ**

# *Проектның продукты:*

**“КАУРЫЙ КАЛӘМ” ГАЗЕТАСЫ, БУКЛЕТ, КАТНАШУЧЫ СЕРТИФИКАТЛАРЫ, ПОРТФОЛИО, ШӘХСИ САЙТ,МӘКТӘП САЙТЫ, ВИЗИТКА, МАТБУГАТ ЯЗМАЛАРЫ БАНКЫ.**

# Кереш

СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН БАЕТУЧЫ ЧАРАЛАР, НӘРСӘ ТУРЫНДА ҺӘМ НИЧЕК СӨЙЛӘШҮ МӨҺИМЛЕГЕ, ФИКЕРНЕҢ ТЫҢЛАУЧЫГА НИ ДӘРӘҖӘДӘ ДӨРЕС ҖИТКЕРЕЛҮЕ ЗАРУРЛЫГЫНА КАГЫЛЫШЛЫ СОРАУЛАР КЕШЕЛӘРНЕ ҺӘРВАКЫТ КЫЗЫКСЫНДЫРГАН.
"ЯШЬ ЖУРНАЛИСТ МӘКТӘБЕ" ИҖАТ ТҮГӘРӘГЕ УКУЧЫЛАРНЫ ХАЛКЫБЫЗНЫҢ РУХИ-ӘХЛАКЫЙ КАНУННАРЫ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРЫРГА, АЛАРДА ЮГАРЫ СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ ФОРМАЛАШТЫРЫРГА, ИҖАДИ СӘЛӘТНЕ ҮСТЕРЕРГӘ, МӨСТӘКЫЙЛЬ УЙЛАРГА ҺӘМ ЭШЛӘРГӘ ОМТЫЛЫШЫН КАНӘГАТЬЛӘНДЕРҮ ЮНӘЛЕШЕНДӘ ЭШ АЛЫП БАРЫРГА МӨМКИНЛЕК БИРӘ. ТҮГӘРӘКТӘ ТАНЫП-БЕЛҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ АРАЛАШУ ФОРМАСЫНДА ОЕШТЫРЫЛА.

БӨТЕН КЕШЕ ДӘ ЯЗУЧЫ, ЖУРНАЛИСТ БУЛА АЛМЫЙ. ӘММА ЯЗМА РӘВЕШТӘ ҮЗ ФИКЕРЕН ЛОГИК ЭЗЛЕКЛЕЛЕКТӘ ӘЙТӘ БЕЛҮ ТАБИБКА, УКЫТУЧЫГА КИРӘК БУЛГАН КЕБЕК, ТӨЗҮЧЕГӘ, ЭШЧЕГӘ ҺӘМ ТЕГҮЧЕГӘ ДӘ БЕР ҮК ДӘРӘҖӘДӘ КИРӘК. ХӘЗЕР КЕШЕНЕҢ РУХИ ДӨНЬЯСЫ, ФИКЕРЛИ БЕЛҮЕ БЕРЕНЧЕ ПЛАНГА ЧЫГА БАРА. ШУҢА КҮРӘ ҮЗ ФИКЕРЕҢНЕ ЭЗЛЕКЛЕ, ДӘЛИЛЛӘП ҺӘМ СУРӘТЛӘП ӘЙТӘ БЕЛҮ, СҮЗЕҢНЕ ДӘЛИЛЛӘП БӘХӘСТӘ КАТНАША АЛУ - БИК КИРӘКЛЕ СЫЙФАТ. ӘЛЕГЕ ПРОЕКТТА КАТНАШУ УКУЧЫЛАРГА ҮЗЛӘРЕНДӘ ӘЛЕГЕ СЫЙФАТЛАРНЫ ҮСТЕРЕРГӘ МӨМКИНЛЕК БИРӘ. ИҢ МӨҺИМЕ ШУЛ: ТӨРЛЕ ИҖАДИ ЭШЛӘР БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНГӘН УКУЧЫЛАРНЫҢ ДӨНЬЯГА ҮЗ КАРАШЛАРЫ, МӨСТӘКЫЙЛЬ ФИКЕРЛӘҮЛӘРЕ БУЛДЫРЫЛА.

# *Төп өлеш. . “Туган телдә яшь журналист мәктәбе”*

УКУЧЫЛАРНЫҢ СӘЛӘТЕН ҺӘМ КЫЗЫКСЫНУЫН ИСКӘ АЛЫП, МӘКТӘБЕБЕЗДӘ ТӨРЛЕ ТҮГӘРӘКЛӘР ЭШЛИ. УКУЧЫЛАР БУ ТҮГӘРӘКЛӘРГӘ БИК ТЕЛӘП ЙӨРИЛӘР. ШУЛАРНЫҢ БЕРСЕ - 5-11 НЧЕ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫ ӨЧЕН "ЯШЬ ЖУРНАЛИСТ МӘКТӘБЕ" ТҮГӘРӘГЕ.
ХӘЗЕР БЕЗ ТОРМЫШЫБЫЗНЫ ИНТЕРНЕТТАН БАШКА КҮЗ АЛДЫНА ДА КИТЕРӘ АЛМЫЙБЫЗ. КӨНКҮРЕШЕБЕЗГӘ, ЭШЧӘНЛЕГЕБЕЗГӘ ИНТЕРНЕТ НЫГРАК ҮТЕП

КЕРГӘН САЕН, УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ДА АНЫҢ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕННӘН ТУЛЫРАК ФАЙДАЛАНЫРГА ТЫРЫША.

МЕНӘ МИН СЕЗНЕ ИНТЕРНЕТ ЧЕЛТӘРЕНДӘ ЯҢА БАРЛЫККА КИЛГӘН МӘГЪЛҮМАТИ ТЕХНОЛОГИЯНЕҢ БЕР ТӨРЕ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРЫП КИТӘСЕМ КИЛӘ. УЛ ВЕБИНАР ДИП АТАЛА. НӘРСӘ СОҢ УЛ ДИГӘНДӘ, **ВЕБИНАР** (ИНГЛ. «WEB-BASED SEMINAR» – ЧЕЛТӘР ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕНӘ НИГЕЗЛӘНГӘН СЕМИНАР, ИНТЕРНЕТ-СЕМИНАР)
УЗГАН ЕЛ МИН ФЕВРАЛЬ АЕННАН БАШЛАП МАЙ АЕНА КАДӘР “АЛТЫН КАЛӘМ” ФЕСТИВАЛЕНЕҢ ИКЕНЧЕ ЭТАБЫНДА КАТНАШТЫМ. БЕЗ КӨН САЕН ДИЯРЛЕК ВЕБИНАР ЭЛЕМТӘГӘ ЧЫКТЫК.ҮЗЕБЕЗНЕ КЫЗЫКСЫНДЫРГАН СОРАУЛАРГА ҖАВАП АЛДЫК,СОРАУ АЛУЛАРДА АКТИВ КАТНАШТЫК, ЖУРНАЛИСТИКАГА КАРАГАН МӨҺИМ ТЕМАЛАРНЫ ӨЙРӘНЕП, ӨЙ ЭШЛӘРЕ БАШКАРДЫК.

МЕНӘ ШУЛ ВЕБИНАР-ОЧРАШУЛАР МИНЕ ҮЗЕБЕЗНЕҢ МӘКТӘБЕБЕЗДӘ ДӘ ШУНДЫЙ ИНТЕРНЕТ АРАЛАШУЛАР ОЕШТЫРУГА ЭТӘРГЕЧ БУЛДЫ.

МИН ИКЕ АЙГА ИСӘПЛӘНГӘН ЭШ ПРОГРАММАСЫ БУЛДЫРДЫМ.ШУЛ ПРОГРАММАГА НИГЕЗЛӘНЕП, МӘКТӘП АДМИНИСТРАЦИЯСЕ ТАРАФЫННАН РАСЛАНГАН НИГЕЗЛӘМӘ ТӨЗЕЛДЕ. БУ ПРОГРАММА НИГЕЗЕНДӘ ЭШЛӘҮ ӨЧЕН, УКЫТУЧЫМ РӘМЗИЯ ГАСЫМ КЫЗЫ ҖИТӘКЛӘГӘН “ЯШЬ ЖУРНАЛИСТ МӘКТӘБЕ” ТҮГӘРӘГЕНӘ ЙӨРҮЧЕ УКУЧЫЛАРДАН ТӨРКЕМ ТУПЛАДЫМ. ӘЛЕГЕ ТӨРКЕМ ТҮБӘНДӘГЕ КАТНАШУЧЫЛАРДАН ГЫЙБАРӘТ: КОЛБАЙ МОРАСА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕНЕҢ 5-11 НЧЕ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫ, НУРЛАТ ШӘҺӘРЕНЕҢ М.Е. СЕРГЕЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ГИМНАЗИЯ УКУЧЫЛАРЫ ҺӘМ ЖУРНАЛИСТИКА ФАКУЛЬТЕТЫН ТӘМАМЛАП, БҮГЕНГЕ КӨНДӘ АТАП ҮТКӘН МӘКТӘПНЕҢ ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ МОСТАФИНА НӘЗИЛӘ КАМИЛ КЫЗЫ, ГАБДУЛЛА КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ МУЗЕЙ ДИРЕКТОРЫ, МАТБУГАТТАГЫ МАТУР ЯЗМАЛАРЫ БЕЛӘН ТАНЫЛГАН ВАЛИУЛЛИНА ЛЮЗИЯ КАМИЛ КЫЗЫ, НУРЛАТ ШӘҺӘРЕ “ДУСЛЫК” РЕДАКЦИЯСЕ КОЛЛЕКТИВЫ, “НУРЛАТ” ТЕЛЕРАДИКОМПАНИЯСЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ. ӘЛЕГЕ ТӨРКЕМ БЕЛӘН МИН, АЛДАН ҖИБӘРЕЛГӘН ССЫЛКА ЯРДӘМЕНДӘ, ВЕБИНАР-ОЧРАШУЛАР УЗДЫРАМ. ВЕБИНАР-ОЧРАШУ АТНАГА ИКЕ ТАПКЫР: ЧӘРШӘМБЕ ҺӘМ ҖОМГА КӨННӘРЕНДӘ УЗДЫРЫЛА.ИКЕ АЙГА 16 МӘРТӘБӘ ОЧРАШУ КАРАЛГАН.

БУ ВЕБИНАР-ОЧРАШУЛАР ВАКЫТЫНДА БЕЗ ЖУРНАЛИСТИКАГА КАГЫЛЫШЛЫ ТӨРЛЕ ТЕМАЛАРГА ӘҢГӘМӘЛӘР ҮТКӘРӘБЕЗ, ЧЫГЫШЛАР ТЫҢЛЫЙБЫЗ, ҮЗЕБЕЗНЕ КЫЗЫКСЫНДЫРГАН СОРАУЛАРГА ҖАВАПЛАР АЛАБЫЗ, ВИРТУАЛЬ ЭКСКУРСИЯЛӘРДӘ БУЛАБЫЗ. ШУНЫСЫ КУАНДЫРА: ЯШЬТӘШЛӘРЕМ БУ ОЧРАШУЛАРДА БИК ТЕЛӘП КАТНАШАЛАР.ТАГЫН БЕР ЯҢАЛЫК: СЕНТЯБРЬ АЕННАН БИРЛЕ “КАУРЫЙ КАЛӘМ” ГАЗЕТАСЫ ТӨРЛЕ МӘКАЛӘЛӘР ҺӘМ ШИГЫРЬЛӘР БЕЛӘН ҮЗ УКУЧЫСЫН ҖӘЛЕП ИТТЕ.БУ ГАЗЕТА АЙГА БЕР ТАПКЫР ЧЫГА. ГАЗЕТАДА БАСЫЛГАН ЯЗМАЛАРНЫҢ ИҢ УҢЫШЛЫЛАРЫ НУРЛАТ РАЙОНЫНЫҢ “ДУСЛЫК” ГАЗЕТАСЫ БИТЛӘРЕНДӘ ДӨНЬЯ КҮРӘ. МӘКАЛӘЛӘРНЕ БАСТЫРУНЫҢ ОТЫШЛЫ ЯГЫ ДА БАР: “КАУРЫЙ КАЛӘМ”ДӘ УРЫН АЛГАН ЯЗМА ӨЧЕН ҺӘРБЕР МӘКАЛӘ АВТОРЫ МӘКТӘП АДМИНИСТРАЦИЯСЕ ИСЕМЕННӘН “КАТНАШУЧЫ СЕРТИФИКАТЫ” АЛСА, “ДУСЛЫК” РАЙОН ГАЗЕТАСЫНДА БАСЫЛГАН ЭШ ӨЧЕН РЕДАКЦИЯ ИСЕМЕННӘН “ ЯЗМА ӨЧЕН СЕРТИФИКАТ” АЛА. ЯНӘ БЕР МӨҺИМ ЯҢАЛЫК: ӘЛЕГЕ ВЕБИНАРДА КАТНАШКАН ЯШЬТӘШЛӘРЕМ КУРС АХЫРЫНДА “КУРС ҮТҮЧЕ ТАНЫКЛЫГЫ”НА ИЯ БУЛА.

ҺӘРБЕР ВЕБИНАР-ОЧРАШУЛАРНЫҢ ЯЗМАСЫ ШӘХСИ САЙТЫМА ҺӘМ ШУЛАЙ УК КОЛБАЙ МОРАСА МӘКТӘБЕ САЙТЫНА УРНАШТЫРЫЛЫП БАРА.

# *Минем портфолио*
































# “ТУГАН ТЕЛДӘ ЯШЬ ЖУРНАЛИСТ МӘКТӘБЕ” ТҮГӘРӘГЕ МӘКТӘП САЙТЫНДА







# *Ахметзянова Айгөлнең шәхси сайтына рәхим итегез!*






# “ZUM” интернет челтәрендә вебинар очрашулар






## ▶ *Кушымта: нигезләмә, эш программасы, проект эше, презентация*



Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Кульбаево-Марасинская средняя общеобразовательная школа
Нурлатского муниципального района Республики Татарстан»

Принято
Педагогическим советом
Протокол №5 от 25.03.2024

«Утверждаю»
Директор МБОУ
«Кульбаево-Марасинская СОШ»
_______ Валеев М.И.
Введено в действие приказом
№ 12 от 25 марта 2024 года


**Положение**
**о проекте «Школа юного журналиста на родном (татарском) языке»**

**1.Цели:**
-развитие творческих и интеллектуальных способностей школьников в области журналистики
-повышение медиакультуры;
-создание единого школьного информационного пространства.

**2.Задачи:**
Проект предоставляет возможность учащимся:
-получить знания в области журналистики;
-принять участие в творческих конкурсах;
-опубликовать свои материалы в школьной газете «Каурый каләм» и на интернет- ресурсах проекта;
-публикация лучших работ в районной газете “Дуслык”;
-проведение онлайн конференций с сотрудниками Телерадиокомпании «Нурлат»,музея имени Габдуллы Кариева, редакции районной газеты “Дуслык”, с обучающимися и педагогами муниципального автономного общеобразовательного учреждения «Нурлатская гимназия имени Героя Советского Союза Михаила Егоровича Сергеева» г. Нурлат Республики Татарстан (связь осуществлять через VK Мессенджер Сферум)
-помочь сформировать портфолио.

**3.Организаторы:**
- Редакция газеты «Дуслык»;
- Телерадиокомпания «Нурлат»;
- Музей имени Габдуллы Кариева;
- Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Кульбаево-Марасинская средняя общеобразовательная школа Нурлатского муниципального района Республики Татарстан".

**4.Участники:** учащиеся 5-11 классов вышеназванных школ, делающие первые шаги в журналистике или желающие научиться писать материалы для печатных и электронных СМИ.



Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы
муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе
“Колбай Мораса урта гомуми белем мәктәбе”

**КИЛЕШЕНГӘН**
Директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары:
_______ Ибрагимова Г.Н.
Протокол № 8
24 март 2024 ел.

**РАСЛЫЙМ**
Мәктәп директоры:
_______ Валеев М.И
Приказ №12
«25» март 2024 ел.

**5-11 нче сыйныф укучылары өчен**
**“Туган телдә яшь журналист мәктәбе”**
**проектының**
**эш программасы**


9 нчы сыйныф укучысы Ахметзянова А.А.,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Галиуллина Р.Г.


**2024 нче ел**


# Кушымта:”Каурый каләм “газетасы, матбугат язмалары банкы





















# Кушымта:сертификатлар






# *Анкета-сораштыру*





*КИЛӘЧӘГЕМ - МИНЕМ КУЛЫМДА. МИН 11 НЧЕ СЫЙНЫФТА УКЫЙМ. КАЙЧАКЛАРДА , БЕРҮЗЕМ ГЕНӘ КАЛЫП ,УЙЛАНЫП УТЫРЫРГА ЯРАТАМ. ҮЗЕННӘН-ҮЗЕ КҮҢЕЛГӘ: “КИЛӘЧӘКТӘ КЕМ БУЛЫРГА? ”- ДИГӘН УЙЛАР КИЛӘ. ТИРӘ-ЯГЫМДА ИСКИТКЕЧ КҮП ПРОФЕССИЯ КЕШЕЛӘРЕ ЯШИ. Ә МИҢА КЕМ БУЛЫРГА? НИНДИ ҺӨНӘР САЙЛАРГА? БАШТА-УЙЛАР ӨЕРМӘСЕ... АЛАР МИНЕ КЫЗЫКТЫРА ДА, ИКЕЛӘНДЕРӘ ДӘ, УЙЛАНДЫРА ДА... СЕЗГӘ СЕРЕМНЕ ЧИШӘР ВАКЫТ ТА ҖИТТЕ... МИН КИЛӘЧӘКТӘ ЖУРНАЛИСТ БУЛЫРГА ҖЫЕНАМ. БҮГЕНГЕ КӨН ТАЛӘПЛӘРЕ БУЕНЧА, МӘКТӘП УКУЧЫСЫ ҮЗ АНА ТЕЛЕН, РУС ТЕЛЕН ҺӘМ БЕР ЧИТ ТЕЛНЕ КАМИЛ БЕЛЕРГӘ ТИЕШ. МИНЕМ ӘНИЕМ ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРНЕ БИК ЯРАТЫП УКЫЙ. БЕЗ “КАЗАН УТЛАРЫ” ЖУРНАЛЫН, ШУЛАЙ УК РЕСПУБЛИКАБЫЗДА ЧЫГА ТОРГАН КҮПСАНЛЫ ГАЗЕТАЛАР ЯЗДЫРЫП АЛАБЫЗ. ӨЙДӘ АЛАРНЫ УКЫГАЧ, ТЕГЕ ЯКИ БУ МӘКАЛӘГӘ КАРАТА ҮЗ ФИКЕРЛӘРЕБЕЗ БЕЛӘН УРТАКЛАШАБЫЗ.*

*МИН АЛДАГЫ ТОРМЫШЫМНЫ ЖУРНАЛИСТИКА БЕЛӘН БӘЙЛИМ ДИГӘН НЫКЛЫ ФИКЕРДӘ КАЛАМ. БУ ПРОЕКТЫМ ДӘВАМЛЫ БУЛАЧАК, ЧӨНКИ ӘЛЕ МИНЕМ ТАГЫН БИШ АЙ МӘКТӘБЕМДӘ БЕЛЕМ АЛАСЫМ, ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕ ҮЗЛӘШТЕРӘСЕМ БАР. ҖӘМГЫЯТЬКӘ ФАЙДАЛЫ ҺӨНӘР ИЯСЕ БУЛУ- ИҢ ЗУР ТЕЛӘГЕМ.*